ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

02 декабрь 2019 ел

**КАРАР**

№ 6217

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Законы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктның 6 һәм 7 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Төзүчеләр тарафыннан күп фатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында хисап бирү формасын һәм тәртибен раслау турында, шул исәптән килешүләр буенча төзелеш проектларын һәм үзләренең йөкләмәләрен гамәлгә ашыруның якынча графикларын, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомостен үтәү турында» 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы Приказы (алга таба – РФ Төзелеш министрлыгының 656/пр номерлы Приказы) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 21.02.2019);

7) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгы нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 28.12.2018, «РФ законнары җыентыгы», 31.12.2018, № 53 (II өлеш), ст. 8712);»;

2) 1.3 пунктның 12-14 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы карары (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 319 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.03.2019, «РФ законнары җыентыгы», 01.04.2019, № 13, ст. 1427);

13) «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә күп фатирлы йортларны төзү (булдыру) өчен гражданнар һәм юридик затлар акчаларын җәлеп итү хокукына ия төзүченең үз акчаларын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 673 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы//ww.pravo.gov.ru, 14.06.2018, «РФ законнары җыентыгы», 18.06.2018, № 25, ст. 3693);

14) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы сайтының адресын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 1133 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1133 номерлы карары) (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 27.09.2018, «РФ законнары җыентыгы», 01.10.2018, № 40, ст. 6137);»;

3) 1.3 пунктның 16 пунктчасын төшереп калдырырга;

4) 1.6 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2) өлешләп төзү объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта:

төзүче – хуҗалык җәмгыяте:

төзүче, (яки) техник заказчы сыйфатында һәм (яки) генераль подрядчы сыйфатында төзелеш подрядының килешүе нигезендә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә шундый күп фатирлы йортларны файдалануга тапшыруга алынган рөхсәтләре булган очракта, барлыгы гомуми мәйданы биш мең квадрат метрдан ким булмаган күп фатирлы йортларны төзүдә (булдыруда) катнашу тәҗрибәсе булган (өч елдан да ким булмаган) төп җәмгыять яисә төп җәмгыятьнең теләсә кайсы бүлендек хуҗалык җәмгыятьләре;

милкендә яки аренда хокукында, субаренда хокукында яисә 161-ФЗ номерлы Федераль законда, РФ Җир кодексының 39.10 статьясының 2 пунктындагы 15 пунктчасында каралган очракларда түләүсез файдалану хокукындагы җир участогы булган һәм төзелеш өчен алынган рөхсәт нигезендә әлеге җир участогында, җитештерү билгеләнешендәге объектлардан тыш, күп фатирлы йортлар һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче;

исемендә «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

Төзүче дигәндә шулай ук Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе башкаласы статусы турында» 1993 елның 15 апрелендәге 4802-1 номерлы Законы нигезендә төзелгән коммерцияле булмаган оешма яки «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә гражданнарның – өлешләп төзүдә катнашучыларның хокукларын яклау буенча җәмәгать-хокук компаниясе турында һәм Россия

Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән фондның оештыру оештыру-хокукый формасындагы унитар коммерцияле булмаган оешма, шулай 214-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 4 булегенең 3 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе субъекты Фонды аңлашыла.»;

5) 1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.7. Төзүче җир участогының шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә, күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүне (булдыруны) төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә, яисә төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзелгән территория яки территорияне комплексль үзләштерү турында килешү яки территорияне комплексль үстерү турында килешү төзелгән (алга таба – төзелешкә берничә рөхсәт) территория чикләрендә урнашкан бер яки берничә җир участогында төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә гамәлгә ашыру шарты белән проект документлары нигезендә, составына өлешләп төзү объектлары керә торган бер яки берничә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә хокуклы. Төзүче, 214-ФЗ номерлы Федераль законының 3 статьясының 1.1 бүлегендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү буенча эшчәнлекне җир участогының берничә шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты буенча яисә төзелгән территорияне үстерү турында берничә килешү һәм (яки) территорияне комплексль үстерү турында килешү һәм (яки) территорияне комплексль үзләштерү турында килешү буенча бер үк вакытта гамәлгә ашырырга хокуклы түгел.»;

6) 1.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.8. Төзүче түбәндәге шартларның берсен үтәгәндә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә күпфатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзүне (булдыруны) гамәлгә ашырырга хокуклы:»;

7) 1.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9. Мондый күп фатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашырганчы, күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алынганнан соң, төзүче өлешләп төзүдә катнашуның башка килешүләре предметы булып тормаган өлешләп төзү объектларына карата өлешләп төзүдә катнашу килешүләрен төзергә хокуклы. Өлешләп төзүдә катнашу килешүләре әлеге бүлектә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып төзелгән очракта, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.2 һәм 4 бүлекләрендә, 15.4 статьясында каралган таләпләр кулланылмый.»;

8) 1.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.12. Дәүләт функциясен үтәгәндә Бүлекнең вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен, килешү буенча өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаларны максатчан файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

2) төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 бүлегендә төзүчегә карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

3) төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясында билгеләнгән мәгълүматны ачу һәм урнаштыруга карата таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

4) төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графиклары үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

5) төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 5 бүлегендә өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаларның исәбен алып баруга карата билгеләнгән таләпләр үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

6) торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яисә мондый бәяләмәне бирүдән дәлилләнгән баш тарту;

7) төзүчедән, ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат – төзүче белән эш итә торган (капиталда биш проценттан артык катнашы булган) физик зат турында мәгълүмат алу;

8) күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләти җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы (алга таба – вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокта төзүчедән, юридик затның тулы исемен яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), адресын (урнашу урынын) күрсәтеп, инженерлык эзләнүләрен, архитектура-төзелеш проектлаштыруны үткәрү һәм төзелеш буенча эшләрне, товарлар белән тәэмин итүне һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы затлар турында, шулай ук мондый товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтү төрләре һәм, Россия Федерациясе законнарында әлеге рөхсәтләрнең (лицензияләрнең) булуы турында таләп каралган очракта, әлеге затларның күрсәтелгән эш, товар белән тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтү төрләрен гамәлгә ашыруга тиешле рөхсәтләре (лицензияләре) булу турында мәгълүмат алу;

9) Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алу;

10) салымнар һәм җыемнар турында законнар үтәлешен контрольдә тоту һәм күзәтчелек итү буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (андагы белешмәләрне), 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 бүлекнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алу;

11) эчке эшләр өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу буенча функцияләрне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 бүлекнең 8 пунктында билгеләнгән таләпләрнең төзүче тарафыннан үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 116.1 статьясының 1 пунктында билгеләрнең таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны алу;

12) дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрын алып баруны һәм Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан һәм аның территориаль органнарыннан төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алу;

13) төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затлардан «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән срокта, күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган мәгълүматларны һәм (яки) документларны алу;

14) төзүчеләрдән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графикларын, килешүләр буенча йөкләмәләренең, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомосте үтәлеше турында кварталлык хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын алу;

15) торак-төзелеш кооперативыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә, торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында, шул исәптән шундый кооператив тарафыннан кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләренең үтәлеше турында кварталлык хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын алу;

16) төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

17) 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру, шул исәптән Россия Федерациясе Үзәк банкына, төзүче белән җаваплылыкны үз өстенә алу килешүе төзегән банкның яки төзүче белән иминият килешүе төзегән иминият оешмасының 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килүе турында мәгълүмат бирү хакында запрослар җибәрү, шулай ук гражданнарның һәм юридик затларның 214-ФЗ номерлы Федераль законны бозуга бәйле шикаятьләрен карап тикшерү;

18) күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче затларга 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, шулай ук күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән башка таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр җибәрү һәм шундый кимчелекләрне бетерү срокларын билгеләү, шул исәптән «Төзүчеләр бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшкәндә гражданнарның – өлешләп төзүдә катнашучыларның хокукларын яклау буенча җәмәгать-хокук компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясының 5.2 бүлегенең 1 һәм 2 пунктлары нигезендә «Гражданнарның – өлешләп төзүдә катнашучыларның хокукларын яклау фонды» җәмәгать-хокук компаниясеннән белдерү кәгазе алынган очракта;

19) Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында http://nabchelny.ru/, карау мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән чикләнгән мәгълүматлардан тыш, төзүче, торак-төзелеш кооперативы эшчәнлегенә үткәрелгән тикшерүләр турында мәгълүмат урнаштыру, шулай ук 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозган өчен төзүчене, аның вазыйфаи затларын җаваплылыкка тарту турында законлы көченә кергән карарлар турында мәгълүматлар, Россия Федерациясе Торак кодексы таләпләрен һәм законнарда билгеләнгән таләпләрне бозган өчен торак-төзелеш кооперативын административ җаваплылыкка тарту турында мәгълүматлар урнаштыру;

20) төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларны (аларның вазыйфаи затларын), торак-төзелеш кооперативларын (аларның вазыйфаи затларын) 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясе законнарыда билгеләнгән җаваплылыкка тарту өчен кирәкле чаралар күрү;

21) өлешләп төзүдә катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук күп фатирлы йорт төзүдә үз акчалары белән катнашкан торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының Россия Федерациясе Торак кодексының 11 бүлегендә каралган хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча гаризалар белән судка мөрәҗәгать итү (шундый хокуклар һәм мәнфәгатьләр бозылган очракта);

22) җинаять эше кузгату турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен, җинаять җәзасы бирелә торган эшләр билгесе булган мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары ачыклануга бәйле материалларны хокук саклау органнарына җибәрү;

23) төзүченең күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыруны билгеле срокка туктату турындагы гариза белән яисә 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 15 һәм 16 бүлекләрендә билгеләнгән очракларда, төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затларны ликвидацияләү турындагы гариза белән арбитраж судына мөрәҗәгать итү;

24) төзүчеләрнең күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген контрольдә тоту турында 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлеген җайга салучы федераль законнар нигезендә шундый кооперативлар тарафыннан күп фатирлы йортлар төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне контрольдә тотуны (күзәтчелекне) гамәлгә ашыру;

25) торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясының 1 бүлегендә алар тарафыннан мәгълүмат һәм документлар урнаштыруга карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

26) Россия Федерациясе Торак кодексының 123.2 статьясының 4 бүлеге нигезендә, торак-төзелеш кооперативының күп фатирлы йорт төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшерүне гамәлгә ашыру;

27) торак-төзелеш кооперативыннан һәм кооператив белән күп фатирлы йорт төзүгә бәйле килешүләр төзегән башка затлардан «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән срокта, торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күп фатирлы йорт төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган документларны һәм мәгълүматны алу;

28) торак-төзелеш кооперативының идарә органнарыннан ачыкланган кимчелекләрне бетерүне таләп итү;

29) гражданнарның һәм юридик затларның торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясының 3 бүлегендәге (киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясындагы таләпләр бозылуга бәйле шикаятьләрен карап тикшерү;

30) торак-төзелеш кооперативына Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясының 3 бүлегендәге (киләчәктә күп фатирлы йортны карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясындагы таләпләрне бозуларны бетерү турында үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр җибәрү һәм мондый кимчелекләрне бетерү срокларын билгеләү;

31) ачыкланган кимчелекләрне бетерү турындагы күрсәтмә билгеләнгән срокта торак-төзелеш кооперативы тарафыннан үтәлмәгән очракта, шулай ук әлеге кимчелекләр торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә реаль куркыныч тудырган очракта, торак-төзелеш кооперативы тарафыннан тиешле кимчелекләр бетерелгәнгә кадәр, кооперативның яңа әгъзаларын җәлеп итү буенча торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген туктату турында күрсәтмәләр чыгару, әлеге кооператив тарафыннан күрсәтмәләр үтәлмәгән очракта торак-төзелеш кооперативын ликвидацияләү турындагы таләп белән судка мөрәҗәгать итү;

32) торак-коммуналь хуҗалыгының дәүләт мәгълүмат системасыннан торак-төзелеш кооперативы әгъзалары реестрындагы мәгълүматларны, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясында каралган башка мәгълүматны алу;

33) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.3 статьясының 5 һәм 6.2 бүлегендә күрсәтелгән мәгълүматны торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыру;

34) хокукларны теркәү органына 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.6 бүлегендә каралган белдерү кәгазе җибәрү;

35) күп фатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының (төзелеш проектының) әзерлек дәрәҗәсе һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган счетлардан файдаланмыйча гына өлешләп төзүдә катнашу килешүләрен төзү мөмкинлеге турында бәяләмә (алга таба – критерийларга туры килү турында контрольдә тотучы орган бәяләмәсе) бирү, тиешле карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча, төзүченең критерийларга туры килү турында бәяләмә бирү хакындагы гаризасын, критерийларга туры килү турында контрольдә тотучы орган бәяләмәсен яки контрольдә тотучы орган бәяләмәсен бирүдән баш тарту турында торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру;

36) вәкаләтле банктан төзүчеләргә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы белән килешү буенча билгеләнгән тәртиптә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алуны гамәлгә ашыру.»;

9) 1.14 пунктның бишенче һәм җиденче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- Бүлек тарафыннан планнан тыш тикшерү Акты төзү;»;

«- төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьяларының 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яисә мондый бәяләмә бирүдән нигезле баш тарту;»;

10) 1.14 пунктның сигезенче абзацын төшереп калдырырга;

11) 1.15.2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктча белән тулыландырырга:

«3) реклама таратканда мәҗбүри таләпләр үтәлешен күзәтү.»;

12) 2.1.6 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга;

13) 2.1.6 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яисә мондый бәяләмәне бирүдән нигезле баш тарту - 30 календарь көн»;

14) 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр (планлы тикшерүләр, планнан тыш тикшерүләр):

2.2.1. Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затларга карата планлы тикшерүләр үткәрелми.

2.2.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) күп фатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен, шулай ук күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында, вәкаләтле органның норматив хокукый актларында билгеләнгән башка таләпләрне бозуны бетерү турында Бүлек тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы чыгу, әгәр

мондый срок чыкканчыга кадәр күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче зат тарафыннан күрсәтмәдә күрсәтелгән кимчелекләр бетерелмәгән булса;

2) төзүченең күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында кварталлык хисабын, Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән бухгалтер хисабын (шул исәптән еллык) һәм (яки) проект декларациясен анализлауны үткәрү барышында күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен ачыклау;

3) контрольдә тотучы органга 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, вәкаләтле органның норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнарының актлары таләпләрен бозу фактлары турында гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясының 1 булегендә күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмадан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат керү;

4) төзүченең төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графигыннан алты һәм аннан да күбрәк айга тайпылуы;

5) 214-ФЗ номерлы Федераль законның һәм аның нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының мәҗбүри таләпләрен бозулар ачыкланган очракта, Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы йөкләмәсе нигезендә чыгарылган планнан тыш тикшерү үткәрү турында Бүлек җитәкчесенең (җитәкчесе урынбасарының) приказы (боерыгы);

6) прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе;

7) Бүлеккә вәкаләтле банкның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.2 статьясындагы 4 бүлегендә каралган белдерү кәгазе керү.

Тиешле тикшерү башланганнан соң, аны оештыру өчен сәбәп булып торган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланса яисә мөрәҗәгатьтә яки гаризада күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматлар кертелү билгеләнсә, Бүлек җитәкчесе карары буенча алдан тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

Гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә күрәләтә ялган мәгълүматлар күрсәтелгән очракта, Бүлек гражданнан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән кергән гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле чыгымнарын күрсәтелгән затлардан түләтү турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Планнан тыш тикшерү, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 11 һәм 12 статьяларында билгеләнгән тәртиптә, документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү формасында үткәрелә.

Документар тикшерүне оештыру 294-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла һәм Бүлекнең урнашу урыны буенча үткәрелә.

214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 11 бүлекнең 1, 2, 3.1, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерү, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 12 бүлеге нигезендә

билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән прокуратура органына хәбәр итеп, Бүлек тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

Бүлек җитәкчесенең юридик затны планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында боерыгы имзаланган көнне Бүлек, аны үткәрүне килештерү максатында, юридик затның эшчәнлеге гамәлгә ашырылу урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гаризаны (РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы приказы белән расланган типовой форма нигезендә рәсмиләштерелә) тапшыра яисә почта аша аны тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә. Әлеге гаризага Бүлек җитәкчесенең планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерыгының күчермәсе һәм аны үткәрү өчен нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документлар теркәлә.

Прокурорның яки аның урынбасарының планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында яки аны үткәрүне килештерүне кире кагу турында карары буенча югарыдыгы прокурорга яки судка шикаять бирелергә мөмкин.

Төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүче затка 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 11 бүлекнең 1, 2, 3.1, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.

Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәнең юридик зат тарафыннан үтәлү срогы чыгу планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып торган очракта, мондый тикшерү предметы булып Бүлек тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.»;

15) 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Юридик затка карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Контрольдәге объектлар (эшчәнлек төрләре, контроль төрләре) | Мәҗбүри таләпләрнең формулировкасы | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив хокукый актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, күчемсез милек объектларын төзү | Өлешләп төзүдә катнашу килешүе нигезендә күп фатирлы йортны төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү хокукына түбәндәге таләпләргә җавап биргән төзүче ия:<br>1) проект документлары һәм проект документларына экспертизаның уңай бәяләмәсе булу;<br>2) төзүченең үз акчаларының күләме төзелешнең проект бәясенең кимендә ун процентын тәшкил итәргә тиеш. Төзүченең үз акчаларын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;<br>3) проект декларациясен 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 2 бүлеге нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрү датасына төзүченең 3 статьяның 2.3 бүлеге нигезендә вәкаләтле банкта ачылган банк счетында төзелешнең проект бәясенең кимендә ун проценты күләмендә акчасы булу, яисә күрсәтелгән датага төзүченең вәкаләтле банк белән составына өлешләп төзү объектлары керә торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен төзелешнең проект | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | бәясенең кимендә кырык проценты күләмендә максатчан кредит бирүне күздә тотып кабул ителгән кредит килешүе булу;<br>4) кредитлар, займнар, ссудалар буенча йөкләмәләр булмау, төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле максатчан кредитлардан тыш,<br>5) төзүче тарафыннан, акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр чыгару яки бирү гамәлгә ашырылмаган;<br>6) төзүченең проект декларациясен 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы 2 бүлеге нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрү датасына өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле булмаган йөкләмәләре төзелешнең проект бәясенең бер процентыннан артмый. Әлеге кагыйдә төзүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы нигезендә өлешләп төзү объектының житешсезлекләрен бетерү буенча йөкләмәсенә карата кулланылмый;<br>7) төзүче карамагында булган милек өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен, шулай ук төзүченең өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) бәйле булмаган шәхси йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен файдаланылмый;<br>8) өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча йөкләмәләр юк;<br>9) төзүче финанс тотрыклылыгы нормативларын үти;<br>10) төзүчегә карата юридик зат-төзүчене ликвидацияләү процедуралары үткәрелми;<br>11) юридик зат-төзүчегә карата «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында арбитраж суды карары юк;<br>12) юридик зат-төзүчегә карата административ җәза чарасы буларак аның эшчәнлеген туктату турында арбитраж суды карары юк;<br>13) «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуслы булмаган тәэминатчылар реестрында, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуслы булмаган тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында юридик зат-төзүче турында (шул исәптән юридик затның бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен үтәүче зат турында) төзелеш, реконструкция һәм капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонт өлкәсендә эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү яки шундый төзелешне, реконструкцияне һәм капиталь төзелешне оештыру яисә юридик заттан торак | |

| | | |
|---|---|---|
| | бүлмәләре алу аларның предметы булып торган контрактларда һәм килешүләрдә күздә тотылган бурычларын үтәве өлешендә мәгълүматлар юк.<br>14) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясындагы 28 һәм 29 пунктлар нигезендә алып барыла торган дәүләт яисә муниципаль милектәге җир участогын сату буенча аукционда яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда намуслы булмаган катнашучылар реестрында юридик зат - төзүче турында (шул исәптән юридик затның бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат турында) мәгълүматлар юк.<br>15) юридик зат-төзүченең узган календарь ел өчен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча түләнеп бетмәгән бурычлары, башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары юк (салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кичектерү, өлешләп түләү, инвестиция салым кредиты бирелгән, Россия Федерациясе законнары нигезендә реструктурлаштырылган һәм алар буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә мөрәҗәгать итүченең бу суммаларны түләү бурычы үтәлгән яки түләтү өметсез дип танылу турында законлы көченә кергән суд карары булган суммалардан тыш), аның түләнеп бетмәгән салым күләме бурычлыга – юридик затка карата таләпләрнең җыелма күләменә тигез яисә аннан артып китә, бу «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турында эш кузгату өчен шарт булып тора. Төзүче тарафыннан күрсәтелгән түләнеп бетмәгән салым, бурычларга шикаять бирү гаризасы язылган һәм мондый гариза буенча карар кабул ителмәгән яисә түләнеп бетмәгән салымнарга, бурычларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән шикаять бирү срогы чыкмаган очракта, төзүче билгеләнгән таләпкә туры килә дип санала, Әлеге кагыйдә «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында " 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда кулланылмый);<br>16) төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат, төзүченең коллегиаль башкарма органының әгъзасы булып торган зат яки төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен үтәгән очракта, идарәче компаниянең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат яисә төзүченең бер генә кеше идарә итә торган вакытлы органы (алга таба – төзүченең җитәкчесе), ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат-төзүче белән идарә итүче (капиталда биш проценттан артык катнашы булган) физик зат, төзүченең баш бухгалтеры 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килә;<br>17) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2.1 бүлеге нигезендә төзүче тарафыннан өлешләп төзүнең беренче катнашучысы белән килешү төзегәнгә кадәр төзүченең һәм проект декларациясенең Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бирелгән бәяләмә булу. | |

| | | |
|---|---|---|
| Барлык төзүчеләр (өлешләп төзү объекты төзелешенә рөхсәт алу һәм өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә урнаштыруга яки урнаштырмауга рөхсәт алу срогына карамастан) | Күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзү өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү юридик зат (төзүче) тарафыннан өлешләп төзүдә катнашу килешүе нигезендә түбәндәгеләрдән соң гына башкарыла:<br>1) күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекы төзү өчен рөхсәт алганнан соң;<br>2) төзүче составына өлешләп төзү объектлары керәчәк күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектлары төзү өчен бирелгән җир участогына шәхси милек хокукына яисә аренда килешүенә, субаренда килешүенә яисә «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законда яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясында 2 пунктның 15 пунктчасында каралган очракларда, төзүче мондый җир участогыннан түләүсез файдалану килешүенә дәүләт теркәве узганнан соң;<br>3) проект декларациясен бастырып чыгарганнан соң, урнаштырганнан соң һәм (яки) тәкъдим иткәннән соң | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 бүлеге; РФ Җир кодексының 39.10 статьясы 2 пунктының 15 пунктчасы |
| | Төзүче тарафыннан проект декларациясенә үзгәрешләр кертү:<br>1) төзүче проект декларациясенә төзүче һәм төзелеш проекты турындагы мәгълүматларга, шулай ук проект документларына үзгәрешләр кертү фактларына кагылышлы үзгәрешләрне әлеге мәгълүматлар үзгәргән көннән башлап өч эш көне эчендә кертергә тиеш, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 4.1 бүлегендә каралган очраклардан тыш;<br>2) хисаптан соң килүче айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйча, төзүче, өлешләп төзү объектының төрен (торак йорт, торак булмаган бина, машина урыны) күрсәтеп, шул исәптән компенсация фондына мәҗбүри түләүләр (взнослар) түләү шарты белән яисә эскроу счетларыннан файдаланып төзелгән килешүләрнең санын күрсәтеп төзелгән килешүләрнең саны турында мәгълүматларга кагылышлы (өлешләп төзү объектларының гомуми мәйданы һәм килешү бәясе) үзгәрешләр кертергә тиеш;<br>3) төзүче проект декларациясенә агымдагы елның финанс нәтиҗәсе, соңгы хисап датасына кредит һәм дебитор бурыч күләмнәре турында квартал саен үзгәрешләр кертергә тиеш;<br>4) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 һәм 5 бүлекләрдә күрсәтелгән үзгәрешләр кертелгән проект декларациясе үзгәрешләр кертелгәннән соң биш эш көне эчендә төзүче тарафыннан торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга һәм торак төзелеше бердәм мәгълүмат системасында төзүченең шәхси кабинеты аша Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрелергә тиеш, үзгәрешләр кертелгән проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны файдаланып. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 4-6 бүлекләре; Россия Төзелеш министрлыгының 996/пр номерлы приказы |

| | | |
|---|---|---|
| | Төзүче квартал саен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруы турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектын гамәлгә ашыруның якынча графикларын, килешүләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма ведомостен, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын үтәве турында хисап тапшырырга тиеш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы 6 бүлегенең 6 пункты |
| | Төзүченең коллегиаль башкарма органы, төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы яки идарә итү компаниясе (әгәр дә ул төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкарса) яисә төзүченең вакытлыча коллегиаль башкарма органы (алга таба төзүченең җитәкчесе), төзүченең баш бухгалтеры һәм әлеге вазыйфаларга кандидатлар 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.<br>Төзүче, төзүче җитәкчесенең вәкаләтләрен туктату турында, яңа җитәкче сайлау (билгеләү) турында, шулай ук төзүченең бер генә кеше идарә итә торган вакытлыча башкарма органын төзү турында карарлар кабул ителгән вакыттан башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына хәбәр итәргә һәм әлеге затларның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясы таләпләренә туры килүе турында мәгълүмат тапшырырга тиеш.<br>Түбәндәге затлар төзүченең җитәкчесе яки төзүченең баш бухгалтеры була алмый:<br>1) икътисадый эшчәнлек өлкәсендәге җинаятьләре яисә дәүләт хакимиятенә каршы җинаятьләре өчен суд хөкеме туктатылмаган яки үтәлмәгән зат;<br>2) дисквалификация рәвешендә административ җәзага тартылган дип саналу срогы узмаган зат;<br>3) «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, юридик зат йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылыкка һәм (яки) юридик заттан килгән зыянны түләттерү рәвешендәге җаваплылыкка тартылган зат, әгәр дә зат тарафыннан суд актында билгеләнгән вазыйфаны үтәгән көннән башлап биш елдан ким вакыт узса;<br>4) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2 бүлеге нигезендә проект декларациясен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрү датасына кадәр биш ел дәвамында төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы, арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган зат;<br>5) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2 бүлеге нигезендә проект декларациясен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрү датасына кадәр өч ел дәвамында төзүченең акцияләренең биш процenttан артыгына (өлешенә) турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) хуҗа булган, арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган зат. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | Корпоратив юридик зат – төзүчегә (алга таба - бенефициар хуҗа) турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) ия булган (капиталдагы өлеше биш проценттан артык булган) физик зат 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясындагы 3 бүлектә каралган таләпләргә җавап бирергә тиеш. | |
| | Төзүче 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралганча, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән мәгълүматны иркле алуны тәэмин итә (мәгълүматны ача). Мәгълүмат күрсәтелгән системада (наш.дом.рф) урнаштырылганнан соң ачылган санала. Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүче төзүче түбәндәге мәгълүматны ачарга тиеш:<br>1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясында 1 бүлекнең 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәт;<br>2) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясы 2 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән документлар;<br>3) проект декларациясе<br>4) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бәяләмәсе;<br>5) күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү өчен төзүче тарафыннан кулланыла торган, 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирүче өлешләп төзүдә катнашу килешүе проекты яки мондый килешүләр проектлары;<br>6) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 һәм 15.5 статьяларындагы таләпләр нигезендә өлешләп төзүдә катнашу килешүе буенча өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү шартлары, мондый акчаларны эскроу счетларында урнаштырган очракта;<br>7) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 5 бүлегендә күрсәтелгән документлар;<br>8) төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә (булдырыла) торган, күп фатирлы йортның һәм (яки) күчемсез милек объектының агымдагы төзелешенең хәлен чагылдыра торган фоторәсемнәр);<br>9) җир участогының шәһәр төзелеше планы;<br>10) шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә, капиталь төзелеш объектының урнашу урынын, аңа килү һәм керү юлларын, җәмәгать сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын билгеләп башкарылган җир участогын оештыруны планлаштыру схемасы;<br>11) төзүченең үз акчалары күләмен исәпләү һәм финанс тотрыклылыгы нормативлары турындагы мәгълүматны үз эченә алган документ;<br>12) «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бөлгенлеккә төшү турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында мәгълүматлар;<br>13) шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә капиталь төзелеш объектының төзелә, рекнструкцияләнә башлавы турында хәбәр; | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | 14) төзүченең исәп-хисап счетын ачу яки ябу турында мәгълүматлар, мондый счетның номерын, вәкаләтле банкның һәм аның идентификаторларының (салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәве номеры) исемен күрсәтеп;<br>15) 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка мәгълүмат. | |
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 2, 6, 8-10, 13 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп төзелә торган һәрбер күп фатирлы йортка һәм (яки) башка күчемсез милек объектына карата ачыла. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 2.1 бүлеге |
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 1, 2, 6, 9-11 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын өлешләп төзүдә катнашуда беренче килешүне дәүләт теркәвенә җибәргәнгә кадәр урнаштырылырга тиеш.<br>214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 12, 13, 14 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында бу вакыйга булган көннән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.<br>214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 8 пунктында күрсәтелгән фоторәсемнәр торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында ай саен урнаштырылырга тиеш.<br>214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 11 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар төзүче тарафыннан әлеге системада, арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабын урнаштыру белән бер үк вакытта, квартал саен урнаштырылырга тиеш.<br>214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ачылырга тиешле мәгълүматларга һәм документларга кертелгән үзгәрешләр торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң өч эш көне эчендә урнаштырылырга тиеш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясының 3, 3.1, 3.2, 4 бүлекләре |
| | Төзүченең, килешү дәүләт теркәве узганчыга кадәр, өлешләп төзүдә катнашучыдан бәя түләүне таләп итәргә хакы юк. Килешү бәясен түләү түләүләрне бер тапкыр кертү яки килешүдә билгеләнгән чорда акчалата булмаган түләү юлы белән башкарыла. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 3 бүлеге |
| | Төзүче өлешләп төзү объектын өлешләп төзүдә катнашучыга килешүдә каралган һәм күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты составына яки гомуми файдаланудагы территориягә аерым чыгу юлы булган күп фатирлы йортның блок-секциясе составына керүче өлешләп төзү объектларын төзүче аларга | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 1 бүлеге |

| | |
|---|---|
| тапшырырга тиешле катнашучылар өчен бердәм сроктан соңга калмыйча тапшырырга бурычлы, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 бүлегендә билгеләнгән очрактан тыш | |
| Күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү килешүдә каралган срокта тәмамланмаган очракта, төзүче әлеге срок чыкканчы ике айдан да соңга калмыйча өлешләп төзүдә катнашучыга тиешле мәгълүмат һәм килешүне үзгәртү турында тәкъдим җибәрергә тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясының 3 бүлеге |
| Төзүче өлешләп төзүдә катнашучыга сыйфаты килешү шартларына, техник регламентлар, проект документлары һәм шәһәр төзелеше регламентлары таләпләренә, шулай ук башка мәҗбүри таләпләргә туры килә торган өлешләп төзү объекты тапшырырга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 бүлеге |
| Өлешләп төзү объектын тапшырганда төзүче өлешләп төзүдә катнашучыга өлешләп төзү объектыннан нәтиҗәле һәм куркынычсыз файдалану кагыйдәләре һәм шартлары, өлешләп төзү объектының хезмәт итү срогы һәм аның составына керүче бизәкләү элементлары, инженер-техник тәэмин итү системалары, конструктив элементлар, эшләнмәләр турында кирәкле һәм дөрес мәгълүмат булган өлешләп төзү объектын эксплуатацияләү инструкциясен тапшырырга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1.1 бүлеге |
| Өлешләп төзү объекты өчен гарантия срогы, мондый өлешләп төзү объектының составына керүче технологик һәм инженерлык җиһазларыннан кала, килешү белән билгеләнә һәм биш елдан да ким булмый. Күрсәтелгән гарантия срогы, әгәр дә килешүдә башкача каралмаса, мондый өлешләп төзү объектының составына керүче технологик һәм инженерлык җиһазларыннан кала, өлешләп төзү объектын тапшыру көненнән исәпләнә. Өлешләп төзүдә катнашучылаларга бирелүче өлешләп төзү объекты составына керә торган технологик һәм инженерлык җиһазларына гарантия срогы килешү белән билгеләнә һәм өч елдан да ким булмаска тиеш. Күрсәтелгән гарантия срогы өлешләп төзү объектын тапшыру турында беренче тапшыру актына яисә башка документка кул куйган көннән башлап исәпләнә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 5, 5.1 бүлекләре |
| Өлешләп төзү объектын тапшыру күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыруга билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алынганнан соң гына башкарыла.<br>Күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын файдалануга тапшыруга билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алынганнан соң, төзүче өлешләп төзү объектын килешүдә каралган сроктан да соңга калмыйча | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 2. 3 бүлекләре |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырырга тиеш. Шул ук вакытта, әгәр килешүдә башкача билгеләнмәгән булса, төзүчегә өлешләп төзү объектын тапшыру буенча йөкләмәне вакытыннан алда үтәү рөхсәт ителми | |
| | Төзүче, килешүдә билгеләнгән өлешләп төзү объектын тапшыру срогы житкәнче кимендә бер ай кала яки, әгәр килешүдә өлешләп төзү объектын тапшыру һәм кабул итү вакыты каралган булса, тапшыру һәм кабул итү срогы башланганчы ундүрт эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә, өлешләп төзүдә катнашучыга, килешү нигезендә, күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзелешенең тәмамлануы һәм өлешләп төзү объектының файдалануга тапшыруга әзерлеге турында хәбәр җибәрергә тиеш, шулай ук өлешләп төзүдә катнашучыны өлешләп төзү объектын кабул итүнең зарурлыгы һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясында 6 бүлектә каралган гамәл кылмавы нәтиҗәләре турында кисәтергә тиеш. Хәбәр почта аша салынган документларның исемлеге һәм өлешләп төзүдә катнашучы күрсәткән почта адресы буенча тапшыру турында белдерү кәгазе белән заказлы хат итеп җибәрелергә яки өлешләп төзүдә катнашучыга шәхсән расписка белән тапшырылырга тиеш. Шул ук вакытта өлешләп төзү объектын тапшыру һәм кабул итү срогы башлану төзүче тарафыннан өлешләп төзү объектын өлешләп төзүдә катнашучыга тапшыру килешүендә билгеләнгән сроктан ундүрт көннән дә иртәрәк һәм бер айдан да соңга калмыйча билгеләнергә тиеш түгел. Килешү нигезендә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзеп бетерү (булдыру) һәм өлешләп төзү объектының тапшыруга әзерлеге турында төзүчедән хәбәр алган өлешләп төзүдә катнашучы, килешүдә каралган срокта яки андый срок билгеләнмәгән булса, әлеге хәбәр алынган көннән башлап җиде эш көне эчендә аны кабул итүгә керешергә тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 4 бүлеге |
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 бүлектә каралган нигезләүләр буенча килешү өзелгән очракта, төзүче килешү өзелгән көннән башлап егерме эш көне эчендә яки килешү 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1.1 бүлегендә каралган нигезләүләр буенча өзелгән очракта килешү өзелгән көннән башлап ун эш көне эчендә өлешләп төзүдә катнашучыга килешү бәясе исәбеннән түләнгән акчаларны кире кайтарырга тиеш, шулай ук әлеге акчалардан файдаланган өчен бу суммага Россия Федерациясе Үзәк банкының өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан түләнгән акчаларны кире кайтару буенча йөкләмәләрне үтәү көненә гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә процентлар түләргә тиеш.<br>Әлеге процентлар өлешләп төзүдә катнашучы килешү бәясе исәбенә акча яки акчаның бер өлешен керткән көннән башлап төзүченең аларны өлешләп төзүдә катнашучыга кире кайтарып биргән көненә кадәр исәпләнә. Өлешләп төзүдә катнашучы аерым граждан булса, әлеге процентлар төзүче тарафыннан икеләтә күләмдә түләнә. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 2 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | Әгәр дә билгеләнгән вакыт эчендә өлешләп төзүдә катнашучы төзүчегә өлешләп төзүдә катнашучының килешү бәясе исәбенә түләнгән акчасын һәм әлеге акчалардан файдаланган өчен бу суммага процентларын алырга мөрәҗәгать итмәсә, төзүче әлеге срок чыкканнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча, төзүченең урнашу урыны буенча нотариус депозитына акчалардан файдаланган өчен акча һәм процентлар күчерергә тиеш, бу хакта өлешләп төзүдә катнашучыга хәбәр итеlә | |
| | Төзүче килешүне үтәүдән берьяклы рәвештә баш тарткан очракта, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 4 һәм 5 бүлекләрдә каралган нигезләүләр буенча, төзүче өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан килешү бәясе исәбенә түләнгән акчаны, аны өзгән көннән соң ун эш көне эчендә кире кайтарырга бурычлы. Әгәр өлешләп төзүдә катнашучы күрсәтелгән срокта төзүчегә өлешләп төзүдә катнашучының килешү бәясе исәбенә түләнгән акчаларын алу өчен мөрәҗәгать итмәсә, төзүче әлеге акчаларны әлеге срок чыкканнан соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча төзүченең урнашу урыны буенча нотариус депозитына күчерергә тиеш, бу хакта өлешләп төзүдә катнашучыга хәбәр итеlә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 5 бүлеге |
| | Төзүче тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 һәм 5 бүлекләрдә каралган акчаларны кире кайтару срогы яисә әлеге акчаларны нотариус депозитына күчерү срогы бозылган очракта, төзүче әлеге акчалардан файдаланган өчен өлешләп төзүдә катнашучыга шул суммага Россия Федерациясе Үзәк банкының өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан түләнгән акчаларны кире кайтару буенча йөкләмәләрне тиешле үтәү көненә гамәлдә булган рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә процентлар түли. Әлеге процентлар өлешләп төзүдә катнашучыга төзүче тарафыннан акчаларны кире кайтару яисә әлеге акчаларны нотариус депозитына күчерү срогы чыккан көннән соң килүче көннән, өлешләп төзүдә катнашучыга акча кире кайтарылган көнгә кадәр яисә мондый акчаларны нотариус депозитына күчергән көнгә кадәр исәпләнә. Өлешләп төзүдә катнашучы аерым граждан булса, әлеге процентлар төзүче тарафыннан икеләтә күләмдә түләнә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 6 бүлеге |
| | Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, төзүче өлешләп төзүдә катнашучыга 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган һәм әлеге килешүдә күрсәтелгән неустойканы (штрафлар, пенялар) түләргә һәм неустойкадан тыш китерелгән зыянны тулысынча капларга тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы |
| | Ике як тарафыннан өлешләп төзү объектын тапшыру турында тапшыру актына яки башка документка кул куелганчыга кадәр төзүченең йөкләмәләре үтәлгән дип санала алмый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясының 1 бүлеге |
| | «Өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» (алга таба-Фонд) җәмәгать - | 214-ФЗ номерлы Федераль законның |

| | |
|---|---|
| хокук компаниясе запросы буенча, төзүчеләр запрос килгән көннән соң ун көн эчендә Фондка бухгалтерлык (финанс) хисабын һәм мәгълүматларның дөреслеген раслаучы документлар (мәгълүмат) бирергә тиеш | 23.2 статьясының 2 бүлеге |
| Төзүчегә карата юридик затны – төзүчене ликвидацияләү процедуралары үткәрелми | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 2 пункты |
| Юридик зат – төзүчегә карата арбитраж судның «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен, күрсәтелгән Федераль законда каралган очраклардан тыш, кертү турында карары юк | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 3 пункты |
| Юридик зат - төзүчегә карата административ җәза чарасы буларак, аның эшчәнлеген туктату турында арбитраж суды карары юк; | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 4 пункты |
| «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуслы булмаган тәэминатчылар реестрында, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алып барыла торган намуслы булмаган тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында юридик зат-төзүче турында (шул исәптән юридик затның бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен үтәүче зат турында) төзелеш, реконструкция һәм капиталь төзелеш объектларына капиталь ремонт өлкәсендә эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү яки шундый төзелешне, реконструкцияне һәм капиталь төзелешне оештыру яисә юридик заттан торак бүлмәләре алу аларның предметы булып торган контрактларда һәм килешүләрдә күздә тотылган бурычларын үтәве өлешендә мәгълүматлар юк. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 5 пункты |
| Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясындагы 28 һәм 29 пунктлар нигезендә алып барыла торган дәүләт яисә муниципаль милектәге җир участогын сату буенча аукционда яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир участогын арендалау килешүен төзү хокукына аукционда намуслы булмаган катнашучылар реестрында юридик зат - төзүче турында (шул исәптән юридик затның бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен башкаручы зат турында) мәгълүматлар юк. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 2.1 бүлеге нигезендә төзүче тарафыннан өлешләп төзүнең беренче катнашучысы белән килешү төзегәнгә кадәр төзүченең һәм проект декларациясенең Федераль законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бирелгән бәяләмә булу. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 9 пункты |
| | Юридик зат-төзүченең узган календарь ел өчен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча түләнеп бетмәгән бурычлары, башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары юк (салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә кичектерү, өлешләп түләү, инвестиция салым кредиты бирелгән, Россия Федерациясе законнары нигезендә реструктурлаштырылган һәм алар буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә мөрәҗәгать итүченең бу суммаларны түләү бурычы үтәлгән яки түләтү өметсез дип танылу турында законлы көченә кергән суд карары булган суммалардан тыш), аның түләнеп бетмәгән салым күләме бурычлыга – юридик затка карата таләпләрнең җыелма күләменә тигез яисә аннан артып китә, бу «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык турында эш кузгату өчен шарт булып тора. Төзүче тарафыннан күрсәтелгән түләнеп бетмәгән салым, бурычларга шикаять бирү гаризасы язылган һәм мондый гариза буенча карар кабул ителмәгән яисә түләнеп бетмәгән салымнарга, бурычларга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән шикаять бирү срогы чыкмаган очракта, төзүче билгеләнгән таләпкә туры килә дип санала, Әлеге кагыйдә «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында " 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда кулланылмый); | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 7 пункты |
| | Төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат, төзүченең коллегиаль башкарма органының әгъзасы булып торган зат яки төзүченең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен үтәгән очракта, идарәче компаниянең бер генә кеше идарә итә торган башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат яисә төзүченең бер генә кеше идарә итә торган вакытлы органы (алга таба – төзүченең җитәкчесе), ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аша) корпоратив юридик зат-төзүче белән идарә итүче (капиталда биш проценттан артык катнашы булган) физик зат, төзүченең баш бухгалтеры 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә туры килә. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә эскроу счетларында урнаштырмый торган төзүчеләр | Төзелешкә бер рөхсәт нигезендә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен төзелгән барлык килешүләр буенча төзүченең түбәндәге йөкләмәләрен үтәве 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13-15 статьяларында билгеләнгән тәртиптә залог белән тәэмин ителергә тиеш:<br>1) 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм (яки) килешүдә каралган очракларда өлешләп төзүдә катнашучы тарафыннан кертелгән акчаларны кире кайтару;<br>2) өлешләп төзүдә катнашучыга өлешләп төзү объектын тапшыру буенча бурычларны үтәмәү, үтәүне кичектерү яки башка тиешенчә башкармау нәтиҗәсендә аңа китерелгән зыянны каплауга тиешле һәм килешүне бозган өчен штрафлар (штраф, пеня) сыйфатында тиешле акчаларны һәм федераль законнар нигезендә аңа тиешле башка акчаларны түләү. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясының 1 бүлеге |
| | Төзүченең исәп-хисап счеты буенча, 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, акчаларны күчерү һәм исәптән чыгару буенча операцияләр гамәлгә ашырылырга мөмкин. Төзүченең исәп-хисап счетыннан алынган акча түбәндәге максатларда гына кулланыла ала:<br>1) проект документлары нигезендә составларына өлешләп төзү объектлары керә торган бер яки берничә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру);<br>2) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) гамәлгә ашырыла торган җир участокларын милеккә яки арендага сатып алу максатларында түләүләр, мондый җир участоклары өчен аренда түләве түләү, шулай ук рөхсәт ителгән куллану төрен үзгәртү өчен түләү кертү, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә мондый җир участокларында урнашкан биналарны, төзелешләрне, корылмаларны төзү һәм реконструкцияләүне тыюны алган өчен түләү;<br>3) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен проект документациясе әзерләү һәм инженерлык эзләнүләре үткәрү, шулай ук, әгәр мондый экспертизаларны мәҗбүри үткәрү турында таләп федераль законнарда билгеләнгән булса, проект документларына һәм инженерлык эзләнүләренә экспертиза үткәрү, дәүләт экология экспертизасы үткәрү;<br>4) төзүче хокукындагы җир участогы чикләрендә, әгәр бу тиешле проект документациясе белән каралган булса, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын әлеге инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен кирәк булган инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен төзү, реконструкцияләү;<br>5) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 1 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | объектларын инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруга (технологик тоташтыру) түләү;<br>6) стандарт торак төзү максатларында территорияне үзләштерү турында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә төзелгән килешү буенча һәм аны башкару белән бәйле түләүләр, әгәр әлеге килешү буенча стандарт торак төзелеше өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырылса;<br>7) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен истә тотып төзелгән территорияне үстерү турында шәһәр төзелеше эшчәнлеге хакындагы законнар нигезендә кабул ителгән килешү буенча түләүләр, әгәр 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү төзүчегә әлеге килешү нигезендә бирелгән һәм шундый төзелгән территория чикләрендә урнашкан җир участокларында гамәлгә ашырылса;<br>8) шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү буенча түләүләр, шул исәптән стандарт торак төзү максатларында, хокукка ия булучылар инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында килешү буенча, җирле үзидарә органнары инициативасы буенча территорияне комплекслы үстерү турында килешү буенча түләүләр, әгәр 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (ясау) әлеге килешүләр нигезендә, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылса.<br>9) мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, гомуми белем бирү мәктәпләре, шифаханәләр урнаштыру өчен билгеләнгән территорияне планлаштыру, шундый территория чикләрендә транспорт инфраструктурасы объектларын дәүләт яисә муниципаль милегенә түләүсез тапшырган очракта инженер-техник инфраструктура объектлары, социаль инфраструктура объектлары һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (юллар, тротуарлар, велосипед юлларын) төзү һәм (яки) реконструкцияләү буенча документлар әзерләү, әгәр 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 6-8 пунктларында күрсәтелмәгән очракларда, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.1 статьясы таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырылса;<br>10) максатчан кредитлар буенча процентларны һәм бурычның төп суммасын түләү, кредит килешүендә каралган, шул исәптән кредит бирү белән бәйле башка түләүләр һәм күпфатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен процентларны һәм бурычның төп суммасын түләү, (максатчан займ килешүе шартларын бозган өчен штрафлардан (штраф, пенялар) тыш), шулай ук 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 7-9 пунктларында күрсәтелгән очракларда, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең | |

| | | |
|---|---|---|
| | 18.1 пунктындагы таләпләрен исәпкә алып, башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру);<br>11) өлешләп төзүдә катнашу килешүләрен дәүләт теркәвенә алу белән бәйле түләүләр;<br>12) төзүченең исәп-хисап счеты ачылган вәкаләтле банкта ачылган банк счетындагы депозитта вакытлыча буш акча урнаштыру, акча һәм мондый депозит буенча исәпләнгән процентлар төзүченең әлеге акчалар урнаштырылган исәп-хисап счетына кире кайтарылу шарты белән;<br>13) төзүченең исәп-хисап счетындагы акчалар белән операцияләр ясау буенча вәкаләтле банкның хезмәт күрсәтүенә түләү;<br>13.1) акчаны 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2.3-1 бүлеге нигезендә ачылган башка вәкаләтле банктагы счетка күчерү;<br>14) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яки) бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләнә торган салымнарны, җыемнарны һәм башка мәҗбүри взносларны, шул исәптән Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына һәм (яки) бюджеттан тыш дәүләт фондларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри взносларны түләү бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен штрафларны, пеняларны һәм башка санкцияләрне, шулай ук административ штрафларны һәм җинаять законнары тарафынннан билгеләнгән штрафларны түләү;<br>15) компенсация фондына мәҗбүри акча күчерүләр (взнослар) түләү;<br>16) өлешләп төзүдә катнашучыга килешү бәясе исәбенә түләнгән акчаларны, шулай ук әлеге акчалардан өлешләп төзүдә катнашу килешүе өзелгән очракта файдаланган өчен әлеге сумманың процентларын кире кайтару;<br>17) хезмәт хакы түләү, бер үк вакытта тиешле салымнарны, Россия Федерациясе пенсия фондына, Россия Федерациясе социаль иминият фондына, мәҗбүри медицина иминияте Федераль фондына иминият взносларын түләү шарты белән, әгәр әлеге салымнарны һәм взносларны түләү федераль законнарда каралган булса;<br>18) төзүченең бер кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы коммерция оешмасының хезмәт күрсәтүе өчен түләү;<br>19) хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән каралган гарантияләр һәм компенсацияләр бирү белән бәйле акчалата түләүләр;<br>20) өлешләп төзүдә катнашучылар акчасы җәлеп ителгән күп фатирлы йортта һәм башка күчемсез милек объектында торак һәм торак булмаган урыннарны, машина-урыннарын карап тотуга бәйле чыгымнарны, шул исәптән коммуналь хезмәтләр өчен түләү, мондый күчемсез милек объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәт алынган көннән башлап, әгәр әлеге объектларга милек хокукы теркәлмәгән булса;<br>21) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчалары җәлеп ителгән күп фатирлы йортның һәм (яки) башка күчемсез милек объектының дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны түләү;<br>22) башка чыгымнарны, шул исәптән реклама, коммуналь хезмәтләр, элемтә хезмәтләре чыгымнарын, | |

| | | |
|---|---|---|
| | төзүче эшчәнлеген тәэмин итү максатларында төзүченең идарә органнарын һәм хезмәткәрләрен, аларның эш урыннарын һәм оргтехниканы урнаштыруны да кертеп торак булмаган бинаны арендалауга бәйле чыгымнарны түләү. | |
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 13, 17-20 пунктларында каралган чыгымнар төзелешнең проект бәясеннән ун проценттан да артык тәшкил итә алмый, ә төп җәмгыятьләре халыкара финанс хисаплылык стандартлары нигезендә әзерләнгән консолидацияләнгән финанс хисаплылыгын ачучы төзүчеләр өчен әлеге чыгымнар проект бәясеннән егерме проценттан да артык тәшкил итә алмый. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 2 бүлеге |
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1, 3, 4 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән максатларда барлык аванс түләүләренең гомуми күләме проект бәясеннән утыз проценттан артмаска тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 4 бүлеге |
| | Төзүче өлешләп төзүдә катнашучылар тарафыннан түләнә торган акчаларны һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 1 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән аерым һәрбер күп фатирлы йортка һәм (яки) башка күчемсез милек объектына карата чыгымнарны исәпкә алуны тәэмин итәргә тиеш | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 5 бүлеге |
| | Төзүче, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) җәлеп итүгә бәйле эшчәнлектән һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 7.1 бүлегендә күрсәтелгән эшчәнлектән тыш, башка эшчәнлек башкарырга хокуклы түгел | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 6 бүлеге |
| | Төзүче хокуклы түгел:<br>1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 6 бүлегендәге таләпләр нигезендә төзелешкә максатчан кредитлар һәм төзүченең гамәлгә куючылары (катнашучылар) тарафыннан бирелә торган максатчан займнардан тыш, кредитлар, займнар, ссудалар рәвешендә акчалар җәлеп итәргә;<br>2) үз мөлкәтеннән өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен, шулай ук өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (ясауга) төзү белән бәйле булмаган өченче затлар алдында төзүченең үз йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен файдаланырга;<br>3) үз өстенә өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча йөкләмә алырга;<br>4) акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр бастырырга һәм бирергә; | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясының 7 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | 5) заемнар һәм ссудалар бирергә, төзүче тарафыннан аңа карата ул төп җәмгыять булып торган башка төзүчегә бирелә торган максатчан займнардан тыш;<br>6) кыйммәтле кәгазьләр сатып алырга;<br>7) коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар булдырырга, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталларында, башка коммерция һәм коммерцияле булмаган оешмалар милегендә катнашырга, төзүче аларга карата төп җәмгыять булган төзүчеләр – хуҗалык җәмгыятьләре булдырудан тыш;<br>8) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә һәм төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгә (булдыруга) җәлеп итү һәм төзүченең эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле булмаган башка сату-алу килешүе ясарга. | |
| | Төзүче, залог предметы буенча түләтү өчен нигез барлыкка килгән очракта, төзелеп бетмәгән объектка милек хокукын теркәргә тиеш. Төзүче төзелеп бетмәгән объектка милек хокукын дәүләт теркәвеннән баш тартканда, мондый объектка милек хокукын дәүләт теркәве өлешләп төзүдә катнашучы дәгъвасы буенча залог предметына түләттерү турында суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 5 бүлеге |
| | Төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән килешү төзелгәнче, 214 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1-3 бүлекләрендә күрсәтелгән милек төзүче тарафыннан күп фатирлы йорт һәм (яки) күчемсез милекнең составына өлешләп төзү объектлары кергән башка объект төзүгә (булдыруга) максатчан кредит буенча йөкләмәләрне тәэмин итү сыйфатында залогка тапшырылган булса, төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын түбәндәге шартларны бер үк вакытта үтәгәндә җәлеп итү рөхсәт ителә:<br>1) 214 - ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 1-3 бүлекләрендә күрсәтелгән милекне залогта тотучы булып банк тора;<br>2) 214-ФЗ Федераль законның 13 статьясындагы 6 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән залог тотучыдан үз таләпләрен 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 2 бүлеге нигезендә салынган милек исәбенә канәгатьләндерүгә ризалык, шулай ук 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 8 бүлегендә каралган очракта өлешләп төзү объектларына залог хокукын туктатуга ризалык алынган | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 6 бүлеге |
| | Төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә беренче катнашучы белән килешү төзелгәннән соң, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1-3 бүлекләрендә күрсәтелгән милек өлешләп төзүдә катнашучыларның ризалыгыннан башка залогка бирелә алмый, составына өлешләп төзү объектлары кергән күп фатирлы йорт һәм (яки) башка күчемсез милек объекты төзүгә (булдыруга) максатчан кредитны кайтаруны тәэмин итү сыйфатында банкка залог итеп тапшыру очрагыннан кала, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15 | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 7 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | статьясындагы 2 бүлек нигезендә банктан залогка салынган милек исәбенә үз таләпләрен канәгатьлендерүгә һәм өлешләп төзү объектларына хокукны туктатуга ризалык алу шарты белән. | |
| | 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру максатларында, төзүче, төзүче белән төзелгән килешү нигезендә эшләрне башкаручы техник заказчы һәм төзүче белән төзелеш подряды килешүе нигезендә эшләрне башкаручы генераль подрядчы бер үк вәкаләтле банкта банк счетларын ачарга һәм әлеге счетларны кулланып кына үзара исәп-хисап ясарга тиеш. Төзүче бер генә исәп-хисап счетына ия булырга хокуклы. Әгәр төзүче өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын бер яки берничә рөхсәт чикләрендә берничә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүгәгә (булдыру) җәлеп итсә, мондый төзүче төзелешкә рөхсәтләрнең һәрберсенә карата аерым исәп-хисап счетына ия булырга тиеш. Банк счеты (банк счетлары) килешүенә клиентның 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган мәгълүматны вәкаләтле банк тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясындагы 1 бүлегендә күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмага бирүгә ризалыгы турындагы шарт кертелә. Төзүченең банк счетыннан (банк счетларыннан) акча күчерү операцияләре вәкаләтле банк тарафыннан 214-ФЗ номерлы Федераль законның 18.2 статьясында күрсәтелгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.3 бүлеге |
| | Төзүче 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын күп фатирлы йортларны һәм (яки) блоклы төзелештәге өч һәм аннан да күбрәк блоклардан торган торак йортларны өлешләп төзү өчен, әлеге чигерүләр (взнослар) һәм күрсәтелгән акчаларны инвестицияләү хисабына алынган милек хисабыннан формалаштырыла торган компенсация фондына чигерүләрне (взносларны) түләү бурычын үтәү шарты белән, «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль законның 201.1 статьясындагы 1 пунктның 3.1 пунктчасы нигезендә торак бинаны, торак булмаган бинаны һәм 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә машина урынын тапшыруны күздә тотучы өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алганчы, җәлеп итәргә хокуклы | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 4 бүлеге |
| Өлешләп төзү объектын төзүдә катнашуга 2018 елның 1 июленнән соң рөхсәт алган төзүчеләр, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясы нигезендә | Төзүче җир участогының шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә, күрсәтелгән күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүне (булдыруны) төзелешкә бер рөхсәт чикләрендә яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә, яисә төзелгән территорияне үстерү турында килешү төзелгән территория яки территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү яки территорияне комплекслы үстерү турында килешү төзелгән (алга таба – төзелешкә берничә рөхсәт) территория чикләрендә урнашкан бер яки берничә җир участогында төзелешкә бер яки берничә рөхсәт чикләрендә гамәлгә ашыру шарты | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| билгеләнгән эскроу-счетларында урнаштырган төзүчеләрдән тыш | белән проект документлары нигезендә, составына өлешләп төзү объектлары керә торган бер яки берничә күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итәргә хокуклы. Төзүче, 214-ФЗ номерлы Федераль законының 3 статьясының 1.1 бүлегендә күрсәтелгән күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү буенча эшчәнлекне җир участогының берничә шәһәр төзелеше планы яки территорияне планлаштыруның расланган проекты буенча яисә төзелгән территорияне үстерү турында берничә килешү һәм (яки) территорияне комплекслы үстерү турында килешү һәм (яки) территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү буенча бер үк вакытта гамәлгә ашырырга хокуклы түгел. | |
| | Төзүче, түбәндәге шартларның берсен үтәгәндә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, бер яки берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзүне (булдыруны) тормышка ашырырга хокуклы:<br>1) 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 4 бүлекнең таләпләрен үтәү;<br>2) өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 статьясында каралган тәртиптә урнаштыру. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.2 бүлеге |
| | Проект документлары һәм проект документлары экспертизасының бәяләмәсе булу | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1 пункты |
| | Төзүченең үз акчаларының күләме проект бәясенең кимендә ун процентын тәшкил итәргә тиеш. Төзүченең үз акчаларын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.1 пункты |
| | Төзүченең проект декларациясен 214-ФЗ Федераль законның 19 статьясындагы 2 бүлеге нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрү датасына, төзүченең вәкаләтле банкта 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 2.3 бүлеге нигезендә ачылган банк счетында төзелешнең проект бәясенең кимендә ун проценты күләмендә акчасы булу, яисә күрсәтелгән датага төзүченең вәкаләтле банк белән күп фатирлы йорт һәм (яки) составына өлешләп төзү төзелеш объектлары кергән башка күчемсез милек объектын төзүгә (булдыруга) төзелешнең проект бәясенең кимендә кырык проценты күләмендә максатчан кредит бирүне күздә тоткан кредит килешүе булу. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.2 пункты |
| | Кредитлар, займнар, ссудалар буенча йөкләмәләр булмау, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү һәм төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) белән бәйле максатчан кредитлардан (максатчан займнардан) тыш. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Төзүче тарафыннан, акцияләрдән тыш, кыйммәтле кәгазьләр чыгару яки бирү гамәлгә ашырылмаган | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.4 пункты |
| | Төзүченең өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү һәм төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) белән бәйле булмаган йөкләмәләре проект декларациясен 214-ФЗ Федераль законның 19 статьясындагы 2 бүлеге нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрү датасына төзелешнең проект бәясеннән бер процентган артмый. Әлеге кагыйдә төзүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы нигезендә өлешләп төзү объектындагы җитешсезлекләрне бетерү буенча йөкләмәләренә карата кулланылмый | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.5 пункты |
| | Төзүче карамагындагы милек өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү өчен, шулай ук төзүченең өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү һәм төзелешкә бер рөхсәт яисә төзелешкә берничә рөхсәт чикләрендә күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) белән бәйле булмаган шәхси йөкләмәләрен үтәү өчен файдаланылмый. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.6 пункты |
| | Төзүченең өченче затларның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү буенча йөкләмәләре юк. Әлеге таләп 2017 елның 1 гыйнварына 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән һәм «Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 1 июлендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба 175-ФЗ номерлы Федераль закон) үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән килешүләр буенча поручитель булып торучы һәм 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 2 бүлекнең 1.7 пунктында билгеләнгән таләпкә туры килә дип саналучы төзүчеләргә кагылмый, әгәр андый төзүчеләрнең өченче затларның йөкләмәләрен тәэмин итү буенча башка йөкләмәләре булмаса. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.7 пункты;<br>175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 6 бүлеге |
| | Төзүче финанс тотрыклылыгы нормативларын үти | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы 2 бүлегенең 1.8 пункты |
| Өлешләп төзү объектын төзүдә катнашуга 2018 елның 1 июленә кадәр рөхсәт алган төзүчеләр, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын 214-ФЗ | Устав (җыелма) капиталы, юридик зат - төзүченең устав фонды (алга таба - төзүченең устав капиталы) тулысынча түләнергә һәм ул түбәндәге суммадан ким булмаска тиеш:<br>1) төзүченең һәм төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы бер мең биш йөз квадрат метрдан артмаган очракта ике миллион биш йөз мең сумнан;<br>2) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 2.1 бүлеге (218-ФЗ номерлы, 175-ФЗ номерлы Федераль законнар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча) |

| | | |
|---|---|---|
| номерлы Федераль законның 15.4 статьясы нигезендә билгеләнгән эскроу счетларында урнаштырган төзүчеләрдән тыш | затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы ике мең биш йөз квадрат метрдан артмаган очракта ун миллион сумнан;<br>3) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы ун мең квадрат метрдан артмаган очракта дүрт миллион сумнан<br>4) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы егерме биш мең квадрат метрдан артмаган очракта кырык миллион сумнан;<br>5) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы илле мең квадрат метрдан артмаган очракта сиксән миллион сумнан;<br>6) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы йөз мең квадрат метрдан артмаган очракта йөз илле миллион сумнан;<br>7) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы ике йөз илле мең квадрат метрдан артмаган очракта дүрт йөз миллион сумнан;<br>8) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы биш йөз мең квадрат метрдан артмаган очракта сигез йөз миллион сумнан;<br>9) төзүченең яки төзүче белән бәйле юридик затларның барлык өлешләп төзү объектларының максималь мәйданы биш йөз мең квадрат метрдан арткан очракта бер миллиард биш йөз мең миллион сумнан. | 175-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 7 бүлеге |
| Торак – төзелеш кооперативы | Торак-төзелеш кооперативы, гражданнардан акча җыю вакытына шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә файдалануга кертелмәгән күп фатирлы йортлар төзү (булдыру) өчен, гражданнарның акчаларын җәлеп итә ала, төзелеш аңа муниципаль милектән яки дәүләт милкеннән түләүсез файдалану өчен бирелгән җир участокларында, шул исәптән «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырылган, яки «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә булдырылган очракта | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 2 бүлегенең 3 пункты |
| | Кооператив әгъзалары хисабына күп фатирлы йорт төзелешен башкаручы торак-төзелеш кооперативы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә, төзүче булып тора һәм, мондый кооперативка төзелешкә бирелгән рөхсәт нигезендә, аның карамагындагы җир участогында күп фатирлы йортны төзүне, реконструкцияләүне тәэмин итә | РФ Торак кодексының 110 статьясының 3 бүлеге |
| | Торак-төзелеш кооперативы, аларны төзү «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда каралган торак-төзелеш кооперативларыннан тыш, бер үк вакытта өч этаждан артык булган бер күп фатирлы йорт төзелешеннән артык төзелеш алып барырга хокуклы түгел. | Торак кодексының 110 статьясының 3 бүлеге |

| | | |
|---|---|---|
| | Кооператив әгъзалары хисабына күп фатирлы йорт төзелешен гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативы 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында (алга таба- бердәм мәгълүмат системасы) кооперативның Уставын, шулай ук түбәндәге документларны һәм мәгълүматны урнаштырырга тиеш:<br>1) торак-төзелеш кооперативы әгъзаларының саны;<br>2) торак-төзелеш кооперативы әгъзалары үз акчалары белән катнаша торган күп фатирлы йортны төзүгә рөхсәт;<br>3) торак-төзелеш кооперативының җир участогына хокуклары, шул исәптән җир участогына хокук билгели торган документ реквизитлары, җир участогы хуҗасы турында мәгълүматлар (торак-төзелеш кооперативы җир участогы хуҗасы булмаса), күп фатирлы йорт төзелеше өчен бирелгән җир участогының кадастр номеры һәм мәйданы, төзекләндерү элементлары турында мәгълүматлар;<br>4) төзелешкә рөхсәт бирүгә нигез булган проект документлары нигезендә әзерләнгән төзелә торган күп фатирлы йортның урнашу урыны һәм аның тасвирламасы;<br>5) төзелә торган күп фатирлы йортта торак бүлмәләр саны, проект документлары нигезендә мондый торак биналарның техник характеристикалары тасвирламасы, шулай ук проект документларына тиешле үзгәрешләр кертелгән очракта күрсәтелгән мәгълүматның үзгәрүе;<br>6) төзелә торган күп фатирлы йортны файдалануга тапшыруга фараздагы рөхсәт алу срогы. | Торак кодексының 123.1 статьясының 1 бүлеге |
| | Торак-төзелеш кооперативы, шул исәптән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында, түбәндәге мәгълүматларны эченә алган үз әгъзаларының реестрын алып барырга тиеш:<br>1) торак-төзелеш кооперативы әгъзасының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда) яисә торак-төзелеш кооперативы әгъзасы юридик зат булса, юридик затның исеме;<br>2) проект документлары нигезендә пай взносын тулысынча түләгән очракта торак-төзелеш кооперативы әгъзасы милек хокукына ия була торган конкрет торак бинаны билгеләү;<br>3) торак-төзелеш кооперативының һәр әгъзасына карата керү һәм пай взнослары күләме. | РФ Торак кодексының 123.1 статьясының 3 бүлеге |
| | Күп фатирлы йорт төзүне кооператив әгъзалары акчалары исәбеннән гамәлгә ашыручы торак-төзелеш кооперативы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына квартал саен торак-төзелеш кооперативы күп фатирлы йортны төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру турында, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм башка затлар алдында үз йөкләмәләрен үтәве турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләнгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән формаларда һәм тәртиптә хисап, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисабы бирергә тиеш. | РФ Торак кодексының 123.2 статьясы 3 бүлегенең 3.3 пункты |

16) 5.1.1 пунктның 1 пунктчасын төшереп калдырырга;

17) 5.1.1 пунктның 2 пунктчасында «планлы тикшерүләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

18) 5.2 һәм 5.2.1 пунктларны төшереп калдырырга;

19) 5.3 пунктта «планлы тикшерүләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

20) 5.3.1 – 5.3.4, 5.3.6 пунктларны төшереп калдырырга;

21) 5.3.9 пунктта «3.3.5 пунктчасында» сүзләрен «2.2.2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

22) 5.3.10 пунктның тугызынчы һәм унынчы абзацларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 11 бүлекнең 1, 2, 3.1, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерү, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясының 12 бүлеге нигезендә билгеләнгән тәртиптә кичекмәстән прокуратура органына хәбәр итеп, контрольдә тотучы орган тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

Төзелеш өчен гражданнарга акча җәлеп итүче затка, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 11 бүлекнең 1, 2, 3.1, 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итү рөхсәт ителми.»;

23) 5.3.11 пунктны «2 бүлегенең 2 пунктында» сүзләре алдыннан «10 статьясы» сүзләре белән тулыландырырга;

24) 5.3.13 пунктны төшереп калдырырга;

25) 5.3.14, 5.3.15 пунктларда «3.3.10 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләрен «5.3.10 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

26) 5.3.16 пунктта «3.3.10 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләрен «5.3.10 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга, «3.4.3 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләрен «2.2.2 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән» сүзләренә алмаштырырга;

27) 5.4 һәм 5.4.1 пунктларда «килешүләр буенча үз йөкләмәләрен» сүзләреннән соң «төзелеш проектының җыелма тупланма ведомостен» сүзләре белән тулыландырырга;

28) 5.4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4.3. Төзүченең кварталлык хисабын анализлаганда, Бүлекнең анализ үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләренең төзүче тарафыннан түбәндәгеләр өлешендә үтәлеше билгеләнә:

1) хисап бирүнең 214-ФЗ номерлы Федераль законда, РФ Төзелеш министрлыгының 656/пр номерлы Приказында билгеләнгән срогының үтәлеше;

2) РФ Төзелеш министрлыгының 656/пр номерлы Приказы нигезендә хисап составының үтәлеше;

3) хисапны рәсмиләштерүгә һәм тутыруга карата РФ Төзелеш министрлыгының 656/пр номерлы Приказында каралган таләпләрнең үтәлеше;

4) төзүче эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләүнең РФ Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары белән билгеләнгән нормативларының үтәлеше;

5) төзелеш проектларын тормышка ашыруның якынча графиклары;

6) өлешләп төзүдә катнашучылар алдында төзүче тарафыннан килешү йөкләмәләрне үтәү сроклары;

7) хисапта бирелгән мәгълүматларның дөреслеге.»;

29) 5.4.5 пунктта «Бүлек белгече тарафыннан чыгарыла» сүзләрен «Бүлек белгече тарафыннан әзерләнә» сүзләренә алмаштырырга һәм «күчемсез милек объектларын» сүзләреннән соң «, Бүлек башлыгы тарафыннан имзалана торган» сүзләре белән тулыландырырга;

30) 5.4.6 пунктта «расписка буенча җитәкчегә (башка вазыйфаи затка яки төзүченең вәкаләтле вәкиленә) тапшырыла яисә тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат белән җибәрелә, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

31) 5.4.7 пунктта «Бүлек белгече тарафыннан күрсәтмә чыгарылган көннән башлап» сүзләрен «Бүлек башлыгы тарафыннан имзаланган көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга һәм «Заказлы хатны тапшыру турында белдерү кәгазе тикшерү материалларына теркәлә.» сүзләрен төшереп калдырырга;

32) 5.5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5.1. Административ процедураны үти башлауга нигез булып төзүчегә, төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә бирү яисә мондый бәяләмә бирүдән нигезле баш тарту тора.»;

33) 5.5.3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Башкарма комитет бәяләмәсе»;

34) 5.5.4 пунктта «РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 11 маендагы 275/пр номерлы боерыгы белән билгеләнгән» сүзләрен «РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы Карары белән расланган» сүзләренә алмаштырырга;

35) 5.5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5.5. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 1, 2, 6, 9-11 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат, күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын өлешләп төзүдә катнашу килешүен дәүләт теркәвенә алуга җибәргәнче, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 12, 13, 14 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат, тиешле вакыйга булган көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш. 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 8 пунктында күрсәтелгән фоторәсемнәр ай саен торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.

214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясындагы 2 бүлекнең 11 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар, бер үк вакытта арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабын урнаштырып, квартал саен төзүче тарафыннан күрсәтелгән системада урнаштырылырга тиеш.»;

36) 5.5.7 пунктта «ай саен» сүзләрен «I, II, III квартал өчен хисап тапшырылганнан соң, айның 10 числосына кадәр квартал саен, IV квартал өчен хисаптан тыш – IV квартал өчен хисап тапшырылганнан соң айның 10 числосына кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

37) 5.6.3 пунктта «планлы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

38) 5.6.4 пунктның 9 пунктчасында «3.5.2 пункты нигезендә» сүзләрен «РФ Торак кодексының 123.2 статьясы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

39) 5.6.8 пунктның «планлы һәм» сүзләрен төшереп калдырырга; «3.3 пунктында билгеләнгән» сүзләрен «2.2 пунктында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

40) 7.10 пунктның икенче абзацында «3.9.7 пунктында» сүзләрен «7.9 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

41) 7.10 пунктның өченче абзацында «5.7 пунктында» сүзләрен «7.9 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

42) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 1 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

43) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

44) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 3 нче кушымтаны, әлеге карарга 3 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

45) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 4 нче кушымтаны, әлеге карарга 4 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (parvo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.


Башкарма комитет
Җитәкчесе


Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 2 декабрендәге
6217 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
1 нче кушымта

«Күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» дәүләт функциясен үтәү буенча
блок-схема






Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 2 декабрендәге
6217 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Төзүченең кварталлык хисабын тикшерү
акты
№ ______ «____» __________ ел

Төзүченең исеме

Хисап чоры:

(вазыйфа) (Фамилия, Исеме, Атасының исеме)

түбәндәге юнәлешләр буенча тапшырылган кварталлык хисапны тикшерү үткәрелде:

| Т/с | Тикшерелә торган мәсьәләләрнең исеме | Тикшерү нәтиҗәсендә билгеләнде |
|---|---|---|
| 1 | Хисапның үз вакытында бирелүе (дата) | |
| 2 | Хисап бирү комплектлылыгы | |
| 3 | Рәсмиләштерү дөреслеге (имзалар, мөһерләр, тегеп кую) | |
| 4 | Кварталлык бухгалтерлык хисабы | |
| 1 нче кушымта | | |
| 5 | Төзүче турында мәгълүматлар | |
| 2 нче кушымта | | |
| 6 | Күчемсез милек объектының исеме | |
| 7 | Күчемсез милек объектының урнашу урыны (төзелеш адресы) | |
| 8 | Күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен тәкъдим ителгән җир участогына хокук турында мәгълүмат | |
| 9 | Төзелешкә рөхсәт турында мәгълүмат | |
| 10 | Өлешләп төзүдә катнашу килешүләре төзелергә мөмкин булган күчемсез милек объекты составындагы мөстәкыйль өлешләрнең гомуми саны | |

| | | |
|---|---|---|
| 11 | Төзүченең һәм проект декларациясенең өлешләп төзү турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында бәяләмәне алу датасына проект декларациясендә күрсәтелгән күчемсез милек объектын төзүнең (булдыруның) планлаштырыла торган бәясе (алга таба - төзелешнең проект бәясе) (млн. сум) | |
| 12 | Хисап чорында төзелешнең проект бәясен үзгәртү | |
| 13 | Хисап датасына төзелешнең проект бәясе | |
| 14 | Хисап датасына төзүче тарафыннан төзелеш проектын тормышка ашыру буенча фактта тотылган чыгымнар, барлыгы (млн. сум) | |
| 15 | Күчемсез милек объектын төзүгә (булдыруга) җәлеп ителгән кредит (заем) акчалары турында мәгълүмат | |
| 16 | Өлешләп төзүдә катнашучыларның күчемсез милек объектын төзүгә (булдыруга) җәлеп ителгән акча күләме турында мәгълүмат | |
| 17 | Күчемсез милек объекты буенча төзелгән өлешләп төзүдә катнашу килешүләре (алга таба - килешү) турында мәгълүмат | |
| 18 | Төзүче тарафыннан килешүләрнең үтәлеше турында мәгълүмат | |
| 19 | Өлешләп төзүдә катнашучыларга өлешләп төзү объектларын тапшыруның күздә тотылган срогы | |
| 20 | Төзелеше тәмамланган күчемсез милек объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт турында мәгълүмат | |
| 21 | Иминият килешүе турында мәгълүмат | |
| 22 | Җаваплылыкны үз өстенә алу килешүе турында мәгълүмат | |
| 23 | Компенсация фондына чигерүләр (взнослар) түләү буенча бурычларны үтәү турында белешмәләр | |
| 3 нче кушымта<br>(нормативларны исәпләү дөреслеге) | | |
| 24 | йөкләмәләрнең тәэмин ителеш нормативы (1 дән ким түгел) | |
| 25 | акчаларны максатчан файдалану нормативы<br>(1 дән артык түгел) | |
| 26 | Төзүченең үз акчалары күләме (төзелешнең проект бәясенең 10 % ким түгел) | |
| 27 | Өстәмә мәгълүмат бирү | |

| | | |
|---|---|---|
| 4 нче кушымта | | |
| 28 | Өлешләп төзүдә катнашу килешүләре буенча төзелеш проектын тормышка ашыру графигын һәм үз йөкләмәләрен үтәү | |
| 5 нче кушымта | | |
| 29 | Төзелешнең җыелма тупланма ведомосте | |
| Тикшерү нәтиҗәсе | | |
| | Хисап (кабул ителде, кабул ителмәде) | |
| 2004 елның 30 апрелендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | | |
| | | |
| РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 12 октябрендәге 626/пр номерлы карары таләпләрен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары таләпләрен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | | |
| | йөкләмәләрнең тәэмин ителеш нормативы (1 дән ким түгел) | |
| | акчаларны максатчан файдалану нормативы (1 дән артык түгел) | |
| | Төзүченең үз акчалары күләме (төзелешнең проект бәясенең 10 % ким түгел) | |
| Проект графигы үтәлешен бозулар ачыкланды, түбәндәгеләр өлешендә: | | |
| | Төзелеш проектын тормышка ашыруның конкрет стадияләре, тормышка ашыруның графикка туры килми торган сроклары | |

Хисапны тикшерде: (имза) ____________________ (Ф.И.А.и.)

Ачыкланган кимчелекләрне бетерүгә күрсәтмә бирелде:

214-ФЗ номерлы Федераль закон – 2004 ел ________________________ кадәр

РФ Төзелеш министрлыгының 656/пр номерлы Приказы – 2018 ________________________ кадәр

РФ Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары – 2018 ________________________ кадәр

Хисапта ачыкланган кимчелекләр бетерелде:

214-ФЗ номерлы Федераль закон – 2004 ел ________________________ (әйе яки юк)

РФ Төзелеш министрлыгының 656/пр номерлы Приказы – 2018 ________________________ (әйе яки юк)

РФ Хөкүмәтенең 1683 номерлы карары – 2018 ________________________ (әйе яки юк)

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 2 декабрендәге
6217 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Төзүче тарафыннан торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында мәгълүмат ачуга карата таләпләр үтәлешен тикшерү
АКТЫ
№ __ «____» __________20___ ел

Төзүче:______________________
(төзүченең исеме)
Урнаштыру: ____________________________
(ИНТЕРНЕТ челтәрендәге адрес)

| Т/с | 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә төзүче тарафыннан мәгълүмат ачу һәм урнаштыру | 214-ФЗ номерлы Федераль законның пункты | Тикшерү нәтиҗәсе |
|---|---|---|---|
| 1. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясының 1 бүлегенең 4 пунктында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәтләр (һәр объект өчен)* | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 1 пункты | |
| 2. | Төзелешкә рөхсәт (һәр объект буенча) * | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 2 пункты | |
| 3. | Проект декларациясе (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 3 пункты | |
| 4. | Төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 бүлекләрендә, 3.2, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмә (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 4 пункты | |
| 5. | Өлешләп төзүдә катнашу килешүенең проекты яки күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын төзү (булдыру) өчен өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү өчен төзүче тарафыннан файдаланыла торган мондый килешүләрнең проектлары (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 5 пункты | |
| 6. | Катнашучыларның акчаларын эскроу счетларында урнаштырган очракта, 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15.4 һәм 15.5 статьялары таләпләре нигезендә өлешләп төзүдә катнашу килешүе буенча | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 6 пункты | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мондый акчаларны җәлеп итү шартлары (һәр объект буенча) | | |
| 7. | Төзүченең еллык бухгалтерлык (финанс) хисабына аудитор бәяләмәсе | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 7 пункты | |
| 8. | Арадаш бухгалтерлык (финанс) хисабы | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 7 пункты | |
| 9. | Өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, төзүче тарафыннан төзелә (булдырыла) торган күп фатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектын төзүнең (булдыруның) агымдагы торышын чагылдыручы фоторәсемнәр | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 8 пункты | |
| 10. | Җир участогының шәһәр төзелеше планы (һәр объект буенча) * | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 9 пункты | |
| 11. | Капиталь төзелеш объектын, подъездларны һәм аңа керү урыннарын, ачык сервитутларның гамәлдә булу зоналары чикләрен, археологик мирас объектларын урнаштыру урыннарын билгеләп, җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыруны оештыру схемасы (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 10 пункты | |
| 12. | Төзүченең үз акчалары күләменең һәм финанс тотрыклылыгы нормативларының исәбе турында мәгълүматны үз эченә алган документ | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 11 пункты | |
| 13. | «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә банкротлык эшендә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында мәгълүматлар | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 12 пункты | |
| 14. | Шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җибәрелгән капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү башлау турында хәбәр (һәр объект буенча) | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 13 пункты | |
| 15. | Мондый счет номерын, вәкаләтле банк һәм аның идентификаторларын (салым түләүченең идентификация номерын, төп дәүләт теркәү номерын) күрсәтеп, төзүченең исәп-хисап счетын ачу турында яки ябу турында мәгълүматлар | 3.1 статьяның 2 бүлегенең 14 пункты | |
| 16. | 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган башка мәгълүмат | | |

*23.3 статьяның 6.3 бүлегендә каралган мәгълүматны торак төзелешенең Бердәм мәгълүмат системасында урнаштыруның техник мөмкинлеге тәэмин ителгәнче, күрсәтелгән мәгълүмат төзүче тарафыннан урнаштырыла

Нәтиҗәләр: 1. ……...

2. ……...

Вазыйфа ______________ /Ф.И.А.и./

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 2 декабрендәге
6217 номерлы карарына
4 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Күп фатирлы йортлар һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуларны бетерү турында күрсәтмә

«__» ________ № ____________

________________________ (үткәрү урыны)

Төзүченең кварталлык хисабын тикшерү акты нигезендә «__» ___________________
_________________________________________________________________________,
(оешманың, органның, юридик затның исеме)

«Күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 6 бүлегенә, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күп фатирлы йортларны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күп фатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 6 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Законына, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, бүлек башлыгы _____________ (Ф.И.А.и.) йөзендә, күрсәтмә бирә

_________________________________________________________________________
(күрсәтмә бирелә торган затның исеме)

«__» ___________ кадәр срокта:

1) кимчелекләрне бетерергә:
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________;
(күрсәтмәнең эчтәлеге, күрсәтмә чыгару нигезе)

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенә күрсәтмәнең үтәлешен раслаучы документларны тапшырырга.

Вазыйфаи зат, юридик зат әлеге күрсәтмәне билгеләнгән срокта үтәмәгән өчен Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының

19.5 статьясының 4 бүлегендә билгеләнгән административ җаваплылыкка тартылырга тиеш.

Күрсәтмәгә күп фатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү турындагы, шулай ук арбитраж судларында суд эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда шикаять бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү әлеге күрсәтмә үтәлешен туктатмый.

Вазыйфаи затның имзасы

___________________ ___________________ ____________________________________________

(вазыйфа) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Күрсәтмә алынды ___________________________________________________________________

(тикшерүче затның фамилиясе, инициаллары, вазыйфасы, дата, имзасы)




Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова